**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**“15 ” апреля 2019 ел** **№ 192**

**““Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”гы Карар проекты турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 44 маддәсе, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставының 99, 100 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2005 елның 8 декабрендәге 19 номерлы Карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына, 1 номерлы кушымта нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы Карар проекты турында”гы Кама Тамагы муниципаль районы Советы Карарына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу Тәртибен, 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча муниципаль район Советының утырышлар залында 13 май 2019 ачык тыңлаулар билгеләргә. Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2018 елның 27 августындагы 148 номерлы Карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә халык алдында тыңлаулар (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә туры китереп ачык тыңлаулар үткәрергә.

4. Әлеге Карарны “Волжские зори”, “Идел таннары” газеталарында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы рәисе урынбасары Г. А. Габидуллинга йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы Советы рәисе Н.А. Вазыйхов**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Совет Карарына 1 номерлы кушымта
15 апреля 2019 ел № ____

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1. 7 маддәнең 1 өлешенең 6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6.2) милләтара һәм конфессияара килешүне ныгытуга, район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен үстерүгә, аз санлы халыкларның һәм башка азчылыкларның хокукларын тормышка ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итүгә, милләтара (этникара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;”.

2. 7.1 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 15 пунктчаны өстәргә:

“15) 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 “Кулланучылар хокукларын яклау турында”гы номерлы Россия Федерациясе Законы белән каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.”.

3. 73 маддәнең 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Муниципаль хокукый актны яки җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгару булып аның тулы текстын Районда таратыла торган вакытлы матбугатта бастырып чыгару санала.

Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук челтәр басмасыннан файдаланырга хокуклы. Рәсми челтәр басмасында муниципаль хокукый актның тулы тексты басылып чыккан (урнаштырылган) очракта, басма басмада аңа күләмле график һәм таблица формасындагы кушымталар китерелергә мөмкин.”.

4. 15маддәнең 2 өлешендә:

беренче абзацта “яки Район Башлыгы” сүзләрен “, Район Башлыгы яки контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы район Башкарма комитеты җитәкчесе” сүзләренә алмаштырырга”;

икенче абзацта “Район Башлыгы” сүзләрен “контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Район Башлыгы яки район Башкарма комитеты җитәкчесе” сүзләренә алмаштырырга.

5. 26 маддәнең 6 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (билгеләнгән тәртиптә теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә, профсоюзта катнашудан тыш, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың гомуми җыелышында, торак, төзелеш, гараж кооперативларында, күчемсез милек милекчеләр иптәшлегендә катнашудан тыш, Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш, оешманың идарә итү органнарында һәм ревизия комиссиясе органнарында (гамәлгә куючы) район мәнфәгатьләрен, муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләр) оештыру яисә идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә кире кайтарылмый торган нигездә тәкъдим итү; федераль законнарда каралган башка очракларда;".

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Совет Карарына 2 номерлы кушымта
15 апреля 2019 ел № ____

# “ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ” МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА”ГЫ КАРАР ПРОЕКТЫНА ГРАЖДАННАРНЫҢ ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ҺӘМ ГРАЖДАННАРНЫҢ АНЫҢ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУДА КАТНАШУЫ ТӘРТИБЕ

1.”Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”ГЫ карар проектына тәкъдимнәр Кама Тамагы районы Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Кама Тамагы штп. Кама Тамагы штп, Калинин урамы, 31 йорт, яисә 2-18-86 факсы буенча, кушымта итеп бирелә торган үрнәк буенча, язма рәвештә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:

| | Пункт | Карар проекты тексты | Текст Проекта автора | Проект тексты, төзәтмәләрне исәпкә алып | Төзәтмәләр авторы (Ф. И. О., адрес, телефон, эш, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8дән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә _________________.

2. Халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар, чыгыш ясау хокукы белән, түбәндәге адрес буенча бирелә: Кама Тамагы штп. Кама Тамагы штп, Калинин урамы, 31 йорт, шәхсән яисә почта аша (“Устав турында фикер алышу” яисә конвертында “ачык тыңлаулар” тамгасы белән), шулай ук 2-18-86 факсы буенча.

Гаризалар эш көннәрендә халык тыңлауларын үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3.Гражданнарның тәкъдимнәре Кама Тамагы муниципаль районы Советы аппараты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм карау өчен муниципаль район Советы Аппаратының юридик бүлегенә тапшырыла.